РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 сентябрь 2018 ел Буа шәһәре № 276/ИК-п

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында
пассажирлар йөртүне оештыру турында»
Нигезләмә турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законнары, “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Россия Федерациясе белән Татарстан Республикасының башка хокукый актлары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында пассажирлар йөртүне оештыру турында» Нигезләмәне расларга (Кушымта).
2. Әлеге Нигезләмә аны рәсми бастырып чыгару көненнән үз көченә керә һәм http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында районның рәсми сайтында һәм шулай ук Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча ТР Муниципаль берәмлекләре порталында бастырып чыгарылырга тиеш
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне үз җаваплылыгымда калдырам.

Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты
башлыгы вазифасын башкаручы И.Г. Гыйззәтов

Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 19 сентябрендәге
276/ИК-п номерлы
карарына кушымта

# ТР БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ПАССАЖИРЛАР ЙӨРТҮНЕ ОЕШТЫРУ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» (алга таба текстта – район) муниципаль берәмлеге халкына транспорт хезмәтен күрсәтү өлкәсендә, районның җирле үзидарә органнары һәм пассажирлар ташуны гамәлгә ашыручы юридик һәм физик затлар арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга сала.

1.2. Әлеге Нигезләмәнең таләпләре районның муниципаль һәм муниципальара даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы, оештыру-хокукый формалары һәм милек формаларына карамастан, барлык затларга, һәм шулай ук юридик зат булып оешмаган шәхси эшмәкәрләр өчен үтәү мәҗбүри.

1.3. Районның муниципаль һәм муниципальара даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы юридик һәм физик затларның төп бурычлары түбәндәгедән гыйбарәт:

- пассажирларны маршрут буенча йөртүдә халык ихтыяҗларын аеруча тулырак канәгатьләндерү;
- пассажирлар йөртүнең куркынычсызлыгын һәм хезмәт күрсәтүнең югары культуралылыгын тәэмин итү;
- транспорт чараларын нәтиҗәле файдалану, хезмәт җитештерүчәнлеген даими күтәрү, транспорт чыгымнарын минималь киметү.

1.4. Әлеге Нигезләмә тәэмин итәргә тиеш:

- хәрәкәт расписаниесе (графигы) белән билгеләнгән срокта, пассажирларны үз вакытында китереп җиткерүне;
- юлда һәм туктау пунктларында кирәкле уңайлыкларны һәм аларга хезмәт күрсәтүнең югары культуралылыгын;
- хәрәкәт куркынычсызлыгын;
- пассажир автотранспортының хәрәкәттәге составы нәтиҗәле файдаланылышын.

1.5. Пассажирлар йөртүне оештыру үз эченә ала:

- пассажирлар агымнарын системалы өйрәнү;
- елына ике тапкырдан да сирәгрәк итмичә (көзге-кышкы һәм язгы-җәйге чорга) муниципаль автобус маршрутларын мәҗбүри рәвештә тикшереп чыгу;
- кирәк булганда яңаларын ачу һәм булган маршрутларның юнәлешләрен үзгәртүне күздә тоткан, рациональ маршрут схемаларын эшләү; маршрутларда хәрәкәттәге составның тибын сайлау һәм санын билгеләү;
- йөртүченең хезмәт режимын рациональ файдалану белән автобуслар хәрәкәтен оештыру системаларын сайлау;
- автобуслар хәрәкәте һәм линиягә хәрәкәттәге составны чыгару расписаниеләрен (графикларын) төзү;
- автотранспортның башка төр пассажир транспорты белән эшен координацияләү;

- транспорт чаралары хәрәкәте белән идарә итү һәм хәрәкәтнең регулярлыгын оператив рәвештә тикшерү;

- районның муниципаль бәйләнеше пассажирлар автотранспортын үстерүнең гамәлдәге һәм перспектив планнарын эшләү;

- барлык муниципаль пассажир транспорты челтәре буенча мәгълүмати-автоматик идарә системасын кертү.

## 2. Төп төшенчәләр һәм терминнар

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр һәм терминнар файдаланыла:

Заказчы – Буа муниципаль районының, муниципаль заказга кертелмәгән, муниципаль даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыруга йөртүче белән килешү төзүче Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты яки аның вәкаләтле органы;

Оештыручы – Заказчы килешү буенча җәлеп итә торган, пассажир транспорты йөртүчеләрнең халыкка транспорт хезмәте күрсәтүен оештыру һәм сыйфатын тәэмин итү буенча функцияләрне башкаручы, юридик яки физик зат;

Йөртүче – әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртипләр нигезендә, расланган маршрутлар буенча пассажирларны йөртүче юридик яки физик зат;

Муниципаль даими йөртүләр маршруты – бер муниципаль берәмлек чикләрендә даими йөртүләр маршруты;

Муниципальара даими йөртүләр маршруты – бер муниципаль районның ике һәм аннан күбрәк җирлекләре чигендә даими йөртүләр маршруты;

Транспорт инфраструктурасы объекты хуҗасы – законлы нигездә транспорт инфраструктурасы объекты хуҗасы булган юридик зат яки шәхси эшмәкәр;

Башлангыч туктау пункты – транспорт чарасының китү вакыты буенча, расписаниедә күрсәтелгән беренче туктау пункты;

Соңгы туктау пункты – расписаниедә күрсәтелгән соңгы туктау пункты;

Туктау пунктының үткәрү сәләте – туктау пунктыннан вакыт берәмлеге эчендә китүен гамәлгә ашырып булган, транспорт чараларының максималь саны;

Транспорт чарасы төре – автобус;

Транспорт чаралары классы – озынлыгы ягыннан билгеле бер габаритлар белән характерланган (аеруча кече класс транспорт чаралары – озынлыгы шул исәптән 5 метрга кадәр, кече класс транспорт чаралары – озынлыгы 5 метрдан шул исәптән 7,5 метрга кадәр, уртача класс транспорт чаралары – озынлыгы 7,5 метрдан шул исәптән 10 метрга кадәр, зур класс транспорт чаралары – озынлыгы 10 метрдан шул исәптән 16 метрга кадәр, аеруча зур класс транспорт чаралары – озынлыгы 16 метрдан артык) транспорт чаралары төркеме;

Рейс – транспорт чарасының башлангыч туктау пунктыннан соңгы туктау пунктына яки соңгы туктау пунктыннан башлангыч туктау пунктына кадәр даими йөртүләр маршруты буенча үтәсе юлы;

Даими йөртүләрнең төре – көйләнә торган тарифлар буенча даими йөртүләр яки көйләнми торган тарифлар буенча даими йөртүләр;

Көйләнгән тарифлар буенча даими йөртүләр – Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары яки җирле үзидарә органнары билгеләгән тарифларны кулланып, һәм юлда йөрү өчен билгеләнгән тәртиптә расланган барлык ташламаларны тәкъдим итеп, пассажирлар йөртүне тормышка ашыру.

Көйләнмәгән тарифлар буенча даими йөртүләр – йөртүче тарафыннан билгеләнгән тарифларны кулланып тормышка ашырылучы даими йөртүләр;

Даими йөртү маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне тормышка ашыру турында таныклык – даими йөртүләр маршрутында көйләнмәгән тарифлар буенча даими йөртүләрне башкару хокукын раслаучы документ;

Даими йөртүләр маршруты картасы – даими йөртүләр маршруты һәм әлеге маршрут буенча йөртүдә файдалануга рөхсәт ителгән транспорт чарасы турында мәгълүматларны үз эченә алган документ;

Дәүләт транспорт контроле органы – транспорт өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек функциясен башкаручы федераль башкарма хакимият органы, яки аның территориаль органы;

Гади иптәшлек килешүендә катнашучылар – гамәлдәге Федераль законда каралган очракларда даими йөртүләрне башкару өчен төзелгән, гади иптәшлек килешүе (уртак эшчәнлек турында килешү) яклары булган юридик затлар һәм (яки) шәхси эшмәкәрләр;

Гади иптәшлек килешүендә вәкаләтле катнашучы – ширкәттәге башка иптәшләре тарафыннан бирелгән ышаныч язуына таянып, яки гади иптәшлекнең язма формадагы килешүе нигезендә, барлык иптәшләре исеменнән өченче затлар белән килешүләр төзергә вәкаләте булган гади иптәшлек килешүендә катнашучы.

Гадәттән тыш хәл – авария яки куркыныч табигать күренеше нәтиҗәсендә барлыкка килгән, аерым төр транспорт эшен туктатып торуга, автомобиль юллары яки аларда урнаштырылган һәм даими йөртүләрне башкаруда файдаланыла торган ясалма юл корылмалары буенча транспорт хәрәкәтен вакытлыча чикләүгә яисә транспорт инфраструктурасы объектлары эшен туктатуга китергән хәл;

Даими йөртүләрнең маршрут паспорты – даими йөртүләр маршруты һәм әлеге маршрут буенча йөртүләр турында мәгълүматларны үз эченә алган документ.

Даими йөртүләрне планлаштыру документы – Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте югары башкарма органының яки муниципаль берәмлек башкарма һәм боеру органының даими йөртүләрне үстерү буенча чаралар исемлеген билгеләүче норматив хокукый акты, аларны оештыру гамәлдәге Федераль закон нигезендә шулай ук Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары һәм җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары компетенциясенә кертелгән.

Транспорт чарасының йөртүләр сыйфатына йогынты ясаучы характеристикалары – идәннең түбән, кондиционер, инвалид булган пассажирларны йөртү өчен җиһазлар, электрон мәгълүмати табло, салонда һава температурасын контрольдә тоту системасы, йөргән өчен саф акчасыз түләү системасы, газ-мотор ягулыгын файдалану өчен җиһазлар булуы һәм башка характеристикалар.

## 3. Муниципаль даими йөртүләр маршрутлары буенча даими йөртүләрне оештыру

3.1. Көйләнә торган муниципаль автобус маршруты Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге чикләрендә башлангыч һәм соңгы пунктлар арасында, район Башкарма комитеты тарафыннан расланган, автобуслар барырга билгеләнгән һәм шулай ук җиһазландырылган юлдан гыйбарәт.

Муниципаль даими автобус маршрутларын ачу, үзгәртү һәм бетерү гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә башкарыла.

Муниципаль даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртү Заказчы, Оештыручы һәм Йөртүче арасында төзелгән килешү, расланган маршрут схемалары, маршрут картасы, маршрут паспорты һәм хәрәкәт расписаниесе (графигы) нигезендә башкарыла.

3.2. Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә гомуми заказ муниципаль даими автобус маршрутлары исемлеген билгеләү юлы белән, гамәлдәге территориядә

халыкның пассажир транспорты хезмәтләрендә ихтыяҗларын аеруча тулырак канәгатьләндерү, пассажир йөртүләрнең куркынычсызлыгын, сыйфатын һәм үтемлелеген тәэмин итү максатында, Заказчы тарафыннан формалаштырыла.

Буа муниципаль районының муниципаль даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыруга килешү төзү хокукына үткәрелгән ачык конкурс нәтиҗәләре буенча, җиңүче белән Буа муниципаль районының муниципаль даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыруга Заказчы, Оештыручы һәм юридик зат һәм (яки) шәхси эшмәкәр булырга мөмкин Йөртүче арасында килешү төзелә. Йөртүчедә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- 8 кешедән күбрәк кешене йөртү өчен җиһазландырылган автомобиль транспортында пассажирлар йөртүгә гамәлдәге законнар нигезендә вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән лицензия;

- гамәлдәге законда билгеләнгән таләпләргә туры килгән персонал (белгечләр, йөртүчеләр, медицина хезмәткәрләре);

- гамәлдәге законнар, муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән конкурс документлары таләпләренә җавап биргән пассажир автомобиль транспорт чаралары;

- техник хезмәт күрсәтү буенча үз милкендәге яки арендаланган база яки аккредитацияләнгән конкрет транспорт предприятиесендә пассажир автомобиль чараларын саклау, хезмәт күрсәтү һәм техник хәлен тикшерүне оештыруга килешүләр;

- башка документлар (пассажирлар йөртү буенча хезмәтнең ярашканлык сертификаты, ОСАГО полисы, автомобиль транспортына техник тикшерү үткәрүгә ярашканлык сертификаты, медицина хезмәткәре сертификаты һ.б.);

Буа муниципаль районының муниципаль заказга кертелмәгән муниципаль даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыруга килешү 7 елга төзелә.

Оештыручы килешү белән бергә Йөртүчегә, район Башкарма комитеты тарафыннан расланган маршрут схемасы, маршрут картасы, маршрут паспорты һәм билгеләнгән үрнәктә хәрәкәт расписаниесен (графигы) бирә.

3.3. Муниципаль даими автобус маршрутларында автобусларның хәрәкәте җыелма хәрәкәт графигы буенча төзелә. Барлык муниципаль автобус маршрутлары челтәре өчен автобусларның җыелма хәрәкәт графигын Оештыручы төзи һәм Заказчы раслый.

3.4. Маршрут паспортларын һәм автобуслар хәрәкәте маршруты схемаларын гамәлдән чыгару Буа муниципаль районының муниципаль заказга кертелмәгән муниципаль даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыру тыелганын аңлата.

Буа муниципаль районының муниципаль заказга кертелмәгән муниципаль даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыруга маршрут паспортларын һәм автобуслар хәрәкәте маршруты схемаларын гамәлдән чыгару йөртүләрне Оештыручы тәкъдиме буенча, килешүдә каралган сәбәпләр булганда, районның Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла, Буа муниципаль районының муниципаль заказга кертелмәгән муниципаль даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыруны үтәгән зат белән килешүне тарката.

Буа муниципаль районының муниципаль даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыруга килешүне таркату өчен өстәмә нигез булып тора:

- маршрутлы пассажирлар йөртү буенча эшчәнлекне регламентлаштырган гамәлдәге законнарның, муниципаль хокукый актларның таләпләрен, яки (һәм) Буа муниципаль районының муниципаль заказга кертелмәгән муниципаль даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыруга килешү шартларын системалы рәвештә бозу;

- маршрутны файдасызлыгы сәбәпле ябу;

- Буа муниципаль районының муниципаль даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыручы юридик затның ябылуы яки үзгәртеп оештырылуы, банкротлыгы яисә шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеге туктатылуы.

Районның Башкарма комитеты зат тарафыннан пассажирлар йөртү башкарылган маршрут паспортын һәм автобуслар хәрәкәте маршруты схемасын, маршрут картасын гамәлдән чыгара һәм әлеге документларның гамәлдән чыгарылуы турында язмача белдерүне йөртүчегә һәм тиешле дәүләт һәм муниципаль органнарга җибәрә.

Йөртүче маршрут паспортын һәм автобуслар хәрәкәте маршруты схемаларын, маршрут картасын йөртүләрне Оештыручыга тапшыра һәм гомуми заказны үтәүне туктата.

3.5. Йөрү өчен түләү.

Муниципаль автобус маршрутында йөргән өчен иң чик тариф Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнә. Йөртүче йөрү өчен түләүне мөстәкыйль рәвештә билгеләргә хокуклы, ләкин ул Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән түләүдән югарырак булмаска тиеш.

Халыкның аерым категорияләренә ташламалы тарифлар буенча яки бушлай пассажирлар йөртү хокукын тәэмин итү һәм йөртүчеләрнең аларны йөртүгә чыгымнарын компенсацияләү мәсьәләләре Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар, Буа муниципаль районының муниципаль заказга кертелмәгән муниципаль даими автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне оештыруга килешү белән көйләнә.

3.6. Заказчының хокукы һәм бурычлары

Заказчының хокукы:

- даими йөртүләрне оештыруны көйләүче, үз компетенциясе чикләрендә норматив хокукый актлар кабул итә;

- үз компетенциясе чикләрендә даими йөртүләрне планлаштыру документын әзерләү тәртипләрен раслый, аны кабул итә һәм тормышка ашыра;

- даими йөртүләр муниципаль маршруты буенча даими йөртүләрнең муниципаль заказчысы функциясен башкара, муниципаль килешү төзи, муниципаль килешү шартлары үтәлеше артыннан тикшерүне башкара, даими йөртүләр маршруты картасын бирә;

- ачык конкурсны оештыручы функцияләрен башкара, ачык конкурста катнашуга заявкалар критериеләрен бәяләү өчен шкаланы билгели, йөртүчеләргә даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне башкару турында таныклык һәм даими йөртүләр маршрутының карталарын бирә, аларның эшчәнлеге артыннан тикшерүне башкара;

- даими йөртүләрнең муниципаль маршрутлары реестрын алып бару тәртибен, даими йөртүләрнең муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, бетерү тәртибен раслый, даими йөртүләрнең муниципаль маршрутлары реестрын алып бара, даими йөртүләрнең муниципаль маршрутларын билгели, үзгәртә һәм бетерә;

- даими йөртүләрнең муниципаль маршрутлары буенча, район территориясендә урнашкан, башлангыч һәм (яки) соңгы туктау пунктлары сыйфатында файдаланырга рөхсәт ителгән туктау пунктлары исемлеген билгели;

- Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча муниципаль берәмлекләр территорияләрендә туктау пунктларын билгеләү буенча тәкъдимнәр җибәрә;

- кирәк булганда даими йөртүләрнең муниципаль маршруты буенча көйләнмәгән тарифлар буенча йөртүне башкаруга таләпләрне билгели;

- даими йөртүләрне башкару һәм аларның үтәлеше артыннан контроль мәсьәләләре буенча федераль башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары белән бәйләнештә тора;

- муниципаль маршрутлы йөртүләр башкаручы пассажир транспортына Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы бюджетларыннан, район бюджетыннан дәүләт ярдәме буенча тәкъдимнәр формалаштыра;

- булган вәкаләтләре чигендә муниципаль маршрут челтәрен төзекләндерү һәм карап тотуны оештыра, муниципаль даими автобус маршрутлары буенча хәрәкәтнең куркынычсызлыгын тәэмин итә;

- Буа муниципаль районы чикләрендә урнашкан ике һәм аннан күбрәк җирлекләр чигендә даими йөртүләр муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару;

- гамәлдәге маршрутларны ел дәвамында кимендә 2 тапкыр тикшереп чыгуны башкара;

- автобусларның соңгы туктау пунктлары (туктап тору урыннары) өчен урыннарны билгеләү;

- пассажир транспортын үстерү республика программаларын эшләү һәм, бу максатларга инвестиция чараларын җәлеп итеп, тормышка ашыру;

- район чикләрендә пассажир йөртүләрне башкаруның куркынычсызлыгын тикшерү буенча дәүләт контроль-күзәтчелек органнарының үзара бәйләнешен тәэмин итү;

- пассажирлы маршрутлы йөртүләр мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән үзара бәйләнеш;

- барлык муниципаль маршрут челтәрләре белән мәгълүмати-автоматлаштырылган идарә системасын кертү һәм катнашу;

- аларның компетенциясенә, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән кертелгән, башка вәкаләтләрне башкара;

- Район халкының шикаятьләрен һәм тәкъдимнәрен карау.

Заказчының бурычлары:

- автомобиль транспортында маршрутлы пассажирлар йөртүне башкаручы йөртүчеләрнең эшчәнлеге артыннан контрольне тәэмин итү;

- маршрут паспортларын, маршрут схемаларын, маршрут карталарын һәм автобус хәрәкәте расписаниеләрен (графикларын) раслау.

Муниципаль даими йөртүләр маршрутын яисә, муниципаль даими йөртүләр маршруты, муниципальара даими йөртүләр маршруты нигезендә алданрак билгеләнгән ике һәм аннан күбрәк уртак туктау пункты булган муниципальара даими йөртүләр маршрутын билгеләү һәм үзгәртү Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы һәм компетенциясенә гамәлдәге маршрутларны раслау кертелгән Заказчы арасында килештерү буенча тормышка ашырыла. Әлеге килештерү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Даими йөртүләр маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм бетерү турындагы карарлар Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органнары рәсми сайтларында яки Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр порталында урнаштырыла.

Әгәр муниципаль даими йөртүләр маршруты, муниципальара даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне башкару турындагы таныклык бирелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр яки гади иптәшлек килешүенең вәкаләтле катнашучысы белән, әлеге таныклыкның гамәлдә булу срогы дәвамында, азрак сроклар килештерелмәгән булса,

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы яки җирле үзидарә вәкаләтле органы инициативасы белән билгеләнгән гамәлдәге маршрутны үзгәртү яки бетерү турындагы карар мондый таныклыкның гамәлдәге срогы тәмамлануга кадәр 180 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм мондый таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамлану белән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы яки җирле үзидарә вәкаләтле органы әлеге пунктның 31 нче абзацы белән каралган, муниципаль даими йөртүләр маршрутын, муниципальара даими йөртүләр маршрутын үзгәртү турында карар кабул иткән көннән 60 көн дәвамында, әлеге маршрутлар буенча йөртүләрне башкару турында таныклык бирелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр яки гади иптәшлек килешүенең вәкаләтле катнашучысы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органына яки җирле үзидарә вәкаләтле органына, мондый таныклыкларның һәм әлеге маршрут карталарының гамәлдә булу вакытын, кабул ителгән карар нигезендә, киләсе срокка озынайту турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә бурычлы.

Муниципальара даими йөртүләр маршрутын билгеләгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы муниципальара даими йөртүләр маршруты реестрын алып баруны тормышка ашыра.

Үз компетенциясе чикләрендә муниципаль даими йөртүләр маршрутын билгеләнгән җирле үзидарә вәкаләтле органы Буа муниципаль районында муниципаль даими йөртүләр маршруты реестрын алып баруны тормышка ашыра.

Даими йөртүләр маршрутлары реестрларына түбәндәге мәгълүматлар кертелергә тиеш:

1) гамәлдәге реестрда даими йөртүләр маршрутының теркәлү номеры;

2) даими йөртүләр маршрутының, аңа гамәлдәге маршрутны билгеләгән федераль башкарма хакимияте вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы яки ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бирелгән тәртип номеры;

3) даими йөртүләр маршруты буенча башлангыч туктау пункты һәм соңгы туктау пункты атамалары рәвешендә яки чикләрендә гамәлдәге маршрут буенча башлангыч туктау пункты һәм соңгы туктау пункты урнашкан җирлек атамалары рәвешендәге, даими йөртүләр маршруты атамасы;

4) даими йөртүләр маршруты буенча арадаш туктау пунктлары атамалары яки чикләрендә арадаш туктау пунктлары урнашкан җирлекләрнең атамалары;

5) даими йөртүләр маршруты буенча туктау пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәте уйланылган урам, автомобиль юллары атамалары;

6) даими йөртүләр маршрутының озынлыгы;

7) пассажирларны транспорт чарасына утырту һәм төшерү тәртибе (бары тик билгеләнгән туктау пунктларында яки, әгәр 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон тыймаса, даими йөртүләр маршруты буенча, Министрлар Советы – Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган «Юл хәрәкәте кагыйдәләре турында» 1993 елның 23 октябрендәге 1090 номерлы карары (алга таба – Юл хәрәкәте кагыйдәләре) тарафыннан расланган юл хәрәкәте кагыйдәләре тыймаган теләсә кайсы урында);

8) даими йөртүләрнең төре;

9) даими йөртү маршруты буенча һәр класстагы транспорт чарасын максималь санда йөртү өчен файдаланылган транспорт чаралары төрләре һәм транспорт чаралары класслары;

10) даими йөртү маршруты буенча йөртү өчен файдаланылган транспорт чараларының экологик характеристикалары;

11) даими йөртүләрне тормышка ашыра башлауның көне;

12) даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне тормышка ашыручы юридик затның атамасы, урнашкан урыны, шәхси эшмәкәрнең (шул исәптән гади иптәшлек килешүе катнашучыларының) исеме, фамилиясе һәм, әгәр булса, әтисенең исеме;

13) һәр туктау пункты өчен планлаштырылган расписание;

14) Россия Федерациясе субъектлары арасында (чиктәш төбәкара даими йөртүләр маршрутларына карата) даими йөртүләрне оештыру турындагы килешүдә яки Татарстан Республикасы законында (муниципальара даими йөртүләр маршрутларына һәм муниципаль даими йөртүләр маршрутларына карата) каралган башка таләпләр.

Даими йөртүләр маршрутлары реестрларына кертелгән мәгълүматлар, вәкаләтләрендә әлеге реестрларны алып бару каралган, федераль башкарма хакимияте вәкаләтле органы, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте вәкаләтле органнары рәсми сайтларында яки җирле үзидарә вәкаләтле органының http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырыла.

Даими йөртүләр маршрутлары реестрларына кертелгән, федераль башкарма хакимияте вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы рәсми сайтларында яки җирле үзидарә вәкаләтле органының http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырылган мәгълүматларны танышу өчен түләү алынмыйча карап булырга тиеш.

Даими йөртүләр маршрутлары реестрларына кертелгән мәгълүматлар (шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны турындагы мәгълүматлардан тыш), вәкаләтләрендә әлеге реестрларны алып бару каралган, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы яки җирле үзидарә вәкаләтле органының Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштырыла.

3.7. Йөртүләрне Оештыручының хокуклары һәм бурычлары.

Оештыручы хокуклы:

- йөртүчеләр белән берлектә, юлларны һәм ясалма корылмаларны төзү һәм төзекләндерүне исәпкә алып, гомуми кулланыштагы транспортта йөртүләрне үстерү, шулай ук автоматик идарә системаларын кертү буенча тәкъдимнәр эшләү;

- яңа автомобиль маршрутларын ачу һәм гамәлдәгеләрен үзгәртү буенча тәкъдимнәр формалаштыру;

- йөртүчеләр белән автобус маршрутларында аларның эшен координацияләү буенча үзара бәйләнешләрне тормышка ашыру;

- автобуста пассажирлар йөртүчеләрнең эшчәнлеге артыннан контрольне тәэмин итү буенча чараларда актив катнашырга;

- йөртүләрнең заказчысы хокукларын үтәүдә катнашырга;

- йөртүчеләргә консультация хезмәтләрен тәкъдим итәргә.

Оештыручының бурычлары:

- халыкның пассажир йөртү маршрутларына ихтыяҗын өйрәнүне оештыру, икътисади файдасын исәпкә алып, гомуми кулланыштагы автомобиль пассажир транспорты маршрут челтәрен үстерү буенча тәкъдимәр эшләп чыгару һәм йөртүләр заказчысына тәкъдимнәр формалаштыру;

- йөртүчеләрнең эшчәнлеген координацияләү максатында, автоматлаштырылган идарә системасын җәлеп итеп, маршруттагы хәрәкәтне диспетчерлык көйләвен гамәлгә ашыру;

- районның контроль-күзәтчелек органнары белән берлектә, хәрәкәтнең даимилеге, транспорт чарасының техник һәм санитар хәле, пассажирларга хезмәт күрсәтү культурасы һәм юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәү күрсәткечләре буенча, йөртүчеләрнең эшенә маршрут (линия) контролен башкару

- йөртүчеләргә муниципаль даими автобус маршрутлары буенча, маршрут паспортлары, схемалары һәм автобус хәрәкәте расписаниеләре (графиклары) төзү һәм оформить итү;

- муниципаль автобус маршрутлары буенча автобуслар хәрәкәтенең җыелма расписаниесен килештерүне оештыру;

- муниципаль автобус маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне башкаручы, оештыру-хокукый формасына һәм милекчелек формасына карамастан, оешмаларга, шулай ук юридик зат оештырмаган шәхси эшмәкәрләргә билет продукциясен сатуны гамәлгә ашыру;

- йөртүчеләрнең йөртү килешүе шартларын үтәвен контрольдә тоту, пассажирлар йөртүне башкаручы пассажир автотранспорты буенча исәп алып бару һәм йөртүләрнең заказчысына вакытында хисап бирү;

- район халкын пассажирлар йөртүне оештыру мәсьәләләре буенча мәгълүмат белән тәэмин итүне башкару.

3.8. Йөртүчеләрнең хокукы һәм бурычлары.

Йөртүчеләрнең хокукы, бурычлары һәм җаваплылыгы, муниципаль даими автобус маршрутларында пассажирлар йөртүне башкарганда аларның заказчы һәм йөртүләрне оештыручы белән үзара мөнәсәбәтләр тәртибе, гамәлдәге законнар, муниципаль хокукый актлар һәм әлеге Нигезләмә һәм йөртүләрнең Заказчысы һәм Оештыручысы белән килешү тарафыннан билгеләнә.

Муниципаль даими автобус маршрутлары буенча йөртүләр башлангыч пункттан соңгы пунктка (туктап тору пунктына) кадәр башкарылырга тиеш. Йөртүченең хокукый һәм хуҗалык мөнәсәбәтләре соңгы пунктлар (туктап тору пунктлары) белән килешүле мөнәсәбәтләре нигезендә билгеләнә.

Йөртүче пассажирларга билгеләнгән үрнәктәге билет продукциясен сатуны тәэмин итә.

Хәрәкәт иминлегенә яки пассажирлар йөртү иминлегенә куркыныч тудырган начар юл яки һава торышы-климатик шартлар буенча, йөртүчегә бәйле булмаган киртәләр барлыкка килүе аркасында хәрәкәт графигы буенча рейслар башкару мөмкин булмаган очраклардан тыш, йөртүче йөртүләрне заказчыга һәм (яки) оештыручыга хәбәр итмичә маршрутта билгеләнгән рейсларны гамәлдән чыгарырга яки хәрәкәт графигын үзгәртергә хокуклы түгел.

Пассажирлар йөртүне башкарган вакытта рөхсәт бирүче һәм башка документлар (лицензия карточкасы, автобуслар хәрәкәтенең расланган расписаниеләре (графиклары), маршрут схемалары, маршрут карталары, юл һәм билет-исәплəү кәгазьләре) автотранспорт чарасында булырга тиеш һәм контрольдә тотучы органнар таләбе буенча йөртүче тарафыннан күрсәтелергә тиеш. Өстә күрсәтелгән әлеге рөхсәт бирүче документацияләрне башка йөртүчеләргә тапшыру тыелган.

Йөртүченең бурычлары:

- көн саен автобус йөртүчеләргә рейска кадәр һәм рейстан соң мәҗбүри рәвештә медицина каравын башкарып, аның үткәрелүен юл кәгазендә тамгалау;

- рейска кадәр техник тикшерү үткәрүгә тиешле квалификация таләпләренә җавап биргән зат тарафыннан көн саен мәҗбүри рәвештә транспорт чарасына техник карау башкару һәм аның үткәрелүе турында юл кәгазендә тамгалау;

- рейска чыгар алдыннан һәр йөртүчене хәрәкәт расписаниесе (графигы) һәм маршрут схемасы, маршрут картасы белән тәэмин итү;

- Юл хәрәкәте кагыйдәләренең 2.1.1 пункты һәм пассажирлар йөртүгә рөхсәт бирүче документацияләр нигезендә, даими рәвештә автобусларны линиягә чыгарыр алдыннан документлар урынында булуын тикшерүне башкару;

- линиядә хәрәкәттәге составның Юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәп эшләве артыннан контроль башкару;

- сыйдырышлык нормаларын үтәү;

- йөртүләр Оештыручыга йөртүче әлеге Нигезләмәне үтәвен контрольдә тоту өчен мәгълүмат җиткерү;

- хәрәкәттәге составның саны үзгәрсә яки маршруттан алынса (сату, исәптән чыгару һ.б.) килешүгә үзгәрешләр кертү өчен йөртүләрне Оештыручыга мәгълүмат җиткерү;

- пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырылуын тәэмин итүче объектларга контроль-күзәтчелек органнарының тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү;

- пассажирдан йөргән өчен түләүне районның Башкарма комитеты карары белән билгеләнгән иң чик тарифтан арттырмыйча алу һәм йөрү бәясе үзгәрүен исәпләр белән тәкъдим итеп һәм маршрут буенча йөрү бәясен дәлилләп, Заказчы һәм (яки) Оештыручы белән килештерү;

- хәрәкәттәге составны махсус билгеләнгән соңгы пунктларда (тукталышларда) тоту. Автобусларны соңгы тукталыш сыйфатында автомобиль юлларының йөри торган өлешендә урнаштыру тыела;

- регламентлы ТО-1, ТО-2 техник хезмәт күрсәтүен, хезмәт күрсәтүгә ярашканлык сертификаты һәм әлеге төрдәге эшләрне үткәрүгә тиешле шартлары булган предприятие шартларында үткәрү;

- исәп алып бару һәм аңа бирелгән вәкаләтләр нигезендә, пассажирлар йөртү Заказчысына һәм Оештыручысына йөртүләр буенча билгеләнгән хисапны үз вакытында җиткерү;

- автоматик идарә системаларын кертүдә турыдан-туры катнашу.

Йөртүченең хокуклары:

- йөртүләрне Оештыручыга юридик һәм башка консультацияләр белән мөрәҗәгать итү;

- пассажирлар йөртүне оештыруны яхшырту буенча тәкъдимнәр кертү;

- башка йөртүчеләрнең маршрутларны әлеге Нигезләмәне бозып файдалануы фактлары ачыкланганда, йөртүләрне Оештыручыга хәбәр итәргә.

3.12. Пассажирның бурычлары һәм хокукы.

Пассажирның хокукы:

- муниципаль маршрут автобусларында үзе белән 7 яшьтән олырак булмаган бер баланы, әгәр ул аерым урын алмаса, бушлай йөртергә;

- автобусларда үзе белән, гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнгән зурлыктагы, кул йөген бушлай йөртергә;

Пассажирның бурычы:

- юл йөрү өчен вакытында түләргә;

- билгеләнгән үрнәктәге юл документларын кондукторның, контроль-ревизия органнарының беренче таләбе буенча күрсәтергә.

Пассажир транспорт чарасының җиһазын һәм инвентарен бозган яки ваткан өчен матди җаваплылык тота.

Китерелгән зыянның холкы турында акт төзелә, анда гаепле зат, тәртип бозуның урыны һәм вакыты, китерелгән зыянның суммасы һәм шулай ук әгәр булса, шаһитлар күрсәтелә.

Пассажир китерелгән зыянның бәясен урында каплаудан баш тарткан очракта, актта шул хакта языла һәм ул зыянны мәҗбүри рәвештә акчалата түләтү өчен нигез булып тора.

Пассажир автомобиль транспортын файдалану кагыйдәләрен бозган өчен гаепле затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылыкка тартыла.

Контроль вакытында әлеге автобуста йөрү яки багаж ташу хокукын бирмәгән билет яки башка юл документларын тәкъдим иткән зат, билетсыз пассажирлар категориясенә кертелә.

Пассажирның багаж ташудагы хокуклары һәм бурычлары шулай ук фрахтовка килешүе шартларында да каралган булырга мөмкин.

## 4. Даими йөртүләр маршрутлары буенча йөртүләрне тормышка ашыру турында таныклык бирү һәм гамәлдән чыгару һәм гамәлдәге маршрут карталарын тапшыру

4.1. Муниципаль даими йөртүләр маршрутлары, муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турындагы таныклык һәм гамәлдәге маршрут карталары, әлеге маршрутларны билгеләгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы яки ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан бирелә.

4.2. Муниципаль даими йөртүләр маршруты, муниципальара даими йөртүләр маршрутры буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турындагы таныклык һәм гамәлдәге маршрут карталары Федераль законда билгеләнгән тәртип буенча ачык бәйге нәтиҗәләре буенча бирелә.

4.3. Ачык конкурс үткәрелмичә генә муниципаль даими йөртүләр маршруты, муниципальара даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турындагы таныклык һәм гамәлдәге маршрут карталары, әгәр алар даими йөртүләрне гамәлгә ашыруга билгеләнгән очракта бирелә:

1) 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясы 11 өлеше яисә 29 статьяның 1 өлеше 1, 2 яки 7 пунктында каралган шартлар барлыкка килгәннән соң, һәм ачык конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча бирелгән даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турында яңа таныклык нигезендә, даими йөртүләрне гамәлгә ашыра башлауга кадәр. 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясы 10 өлешендә каралган шартлар буенча, үтмәгән дип танылган ачык конкурс җиңүчесенә даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турындагы таныклык һәм гамәлдәге маршрут картасы бирү тыела.

2) гадәттән тыш хәл шартларында халыкка транспорт хезмәтен күрсәтүне тәэмин итү максатында билгеләнгән даими йөртүләр маршруты буенча.

Гамәлдәге статьяның 3 өлешендә каралган очракларда, ачык конкурс үткәрмичә генә муниципаль даими йөртүләр маршруты, муниципальара даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турындагы таныклык, гамәлдәге маршрутлар карталары бирелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр, гади иптәшлек килешүендә катнашучылар Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы норматив хокукый акты, ТР Буа муниципаль районы җирле үзидарә органы норматив хокукый акты билгеләгән тәртиптә ачыклана.

4.4. Ачык конкрурс үткәрмичә генә даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турындагы таныклык, даими йөртүләр маршруты карталары аларны бирергә нигез булган шартлар башланган көндә, 180 көннән дә артмаган срокка бер тапкыр бирелә, әгәр бу шарт әлеге маршрут буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру буенча элегрәк бирелгән таныклыкны гамәлдән чыгару булса, әлеге таныклык гамәлдә булуын туктату срогына.

4.5. Даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турындагы таныклыкның гамәлдә булуы 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясы 2-4 өлешләрендә билгеләнгән тәртип буенча, Федераль законның 29 статьясы 1 өлешендә билгеләнгән шартларның берсе генә ачыкланса да туктатыла.

4.6. Даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турындагы таныклык биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте вәкаләтле органы яки җирле үзидарә вәкаләтле органы түбәндәге шартларның берсе генә ачыкланса да, әлеге таныклыкның гамәлдә булуын туктату турындагы гариза белән судка мөрәҗәгать итә:

1) юридик зат, шәхси эшмәкәр, гади иптәшлек килешүенең вәкаләтле катнашучысы даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турында квартал саен хисапны ел дәвамында берничә тапкыр 2015 елның 13 июлендәге Федераль законның 37 статьясы 2 өлешендә каралган срокта бирмәсә;

2) әлеге таныклык бирелгән юридик зат, шәхси эшмәкәр, гади иптәшлек килешүенең бер генә катнашучысы булса да, бу таныклык белән каралган йөртүләрне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексының 11.33 статьясы 4 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән административ хокук бозулар ясаган өчен, бер ел дәвамында берничә тапкыр административ җаваплылыкка тартылган булса;

3) гади иптәшлек килешүен таркату (әгәр бу таныклык гади иптәшлек килешүе катнашучыларына бирелгән очракта);

4) йөртүче гаебе белән кылынган, кеше сәламәтлегенә авыр зыян салуга яки кеше үлеменә китергән, юл-транспорт һәлакәте;

6) 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 7.1 статьясы белән билгеләнгән, көйләнмәгән тарифлар буенча муниципальара даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыруга таләпләрне ел дәвамында икенче тапкыр бозганда.

## 5. Көйләнмәгән тарифлар буенча муниципальара даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыруга таләпләр

5.1. Юридик зат, шәхси эшмәкәр, гади иптәшлек килешүе катнашучысы көйләнмәгән тарифлар буенча муниципальара даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе законнары, гамәлдәге Закон белән билгеләнгән таләпләрне үтәргә, шул исәптән тәэмин итәргә бурычлы:

1) билгеләнгән тәртиптә ГЛОНАСС яки ГЛОНАСС/GPS спутниклы навигация аппаратурасы белән тәэмин ителгән транспорт чараларын файдалану, һәм андый транспорт чараларыннан мәгълүматларны "ГЛОНАСС+112" Бердәм дәүләт мәгълүмати системасына өзлексез (даими йөртүләр маршрутының билгеләнгән расписаниесе чигендә) тапшыру;

2) транспорт чарасында инвалид булган пассажирларны йөртү өчен урнаштырылган җиһазлар, һава температурасын контрольдә тоту системасы, электрон мәгълүмати табло, йөргән өчен саф акчасыз түләү системасының төзек эшен;

3) муниципальара даими йөртүләр маршруты буенча йөртүләргә тарифлар үзгәрү турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына, автовокзал һәм автостанция хуҗаларына, андый тариф үзгәртелгәнче 30 календарь көн кала, язмача формада хәбәр итү;

4) бер квартал дәвамында башкарылмаган рейслар саны һәм расписание белән билгеләнгән гамәлдәге квартал дәвамында башкарылырга тиешле рейслар саны арасындагы максималь мөмкин булган, өч процентган да күбрәк булмаган бәйләнештән чыгып, муниципальара даими йөртүләр маршруты буенча рейслар башкару. Юл хәрәкәтенең башка катнашучылары гаебе белән булган юл-транспорт һәлакатләре, начар һава шартлары яки автомобиль юлларында тоткарлык барлыкка килүеннән транспорт чарасының тизлеге кимүе аркасында башкарылмаган рейслар, навигациянең мәгълүмати системасында техник өзеклекләр аркасында исәпкә алынмаган, шулай ук

гадәттән тыш хәл яки начар метеорологик шартлар булганда автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен өлешчә чикләү яки тулысынча тыю, даими йөртүләр маршруты буенча ремонт-төзелеш эшләрен үткәргәндә юл участогын әйләнеп узу юлы булмау аркасында башкарылмаган рейслар, башкарылмаган булып саналмый.

## 6. Коммерцияле автобус маршрутларында пассажирлар йөртүне оештыру

6.1. Расланган гомуми заказдан тыш өстәмә рәвештә автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртү, мондый йөртүләргә ихтыяҗ булганда, әлеге Нигезләмә таләпләре нигезендә һәм гамәлдәге законнарга каралган тәртип буенча, коммерцияле маршрутлар буенча тормышка ашырыла ала.

Юридик зат яисә шәхси эшмәкәр (алга таба – Йөртүче) коммерцияле пассажир маршруты ачарга хокуклы.

6.2. Йөртүче яңа автобус маршруты ачу максатында районның Башкарма комитетына түбәндәге документларны тәкъдим итә:

а) коммерцияле пассажир маршруты ачу турында гариза, анда күрсәтелергә тиеш:

- юридик зат өчен – тулы атамасы, оештырылу-хокукый формасы, юридик һәм почта адреслары, элемтә өчен телефоны;

- шәхси эшмәкәр өчен – фамилиясе, исеме, атасы исеме, паспорт мәгълүматлары (серия, номер, кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән); яшәү урыны, элемтә өчен телефоны;

- маршрут ачуга белдерелгән туктау пунктлары, хәрәкәттәге составның рейсара туктап тору урыннары атамалары;

- ачылачак маршрутта йөртүче тәкъдим иткән эш режимы;

б) юридик зат өчен – бөтен үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән бергә гамәлгә кую документлары копияләре, юридик затлар дәүләт реестрына кертү турында таныклык копиясе (әгәр копия нотариус тарафыннан расланмаган очракта, оригиналны күрсәтергә);

юридик зат оештырмаган шәхси эшмәкәр өчен – шәхси эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәве турындагы таныклык копиясе (әгәр копия нотариус тарафыннан расланмаган очракта, оригиналны күрсәтергә);

в) 8 дән күбрәк кешене йөртү өчен җиһазландырылган автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүгә вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән лицензиянең тиешенчә расланган копиясе;

г) маршрут ачуның максатчанлыгын дәлилләүче документлар (әлеге маршрут буенча пассажирлар йөртү ихтыяҗын исәпләү (тотрыклы пассажир агымы), маршрут ачуның максатчанлыгын техник-икътисади дәлилләү һәм башкалар);

д) ачарга белдерелгән маршрут паспорты проекты;

е) ачарга белдерелгән, территорияләрендә әлеге маршрут үткән районның җирле үзидарә органнары белән мәҗбүри рәвештә килештерелгән маршрут схемасы проекты;

ж) маршрут буенча пассажир транспорты хәрәкәте расписаниесе (графигы) проекты;

з) маршрут буенча хәрәкәт графигы, автобусның сыйдырышлылык нормалары, хәрәкәт маршруты үтәлеше артыннан диспетчер контролен башкару мөмкинлеген раслаучы документлар;

и) маршрутта пассажирлар йөртүне башкару өчен файдаланылачак транспорт чаралары исемлеге (марка, дәүләт номеры, чыккан елы);

к) персонал, эшчеләр саны, гариза биргән датага булган уртача хезмәт хакы турында мәгълүматлар;

л) тәкъдим ителгән документларның исемлеге.

6.3. Районның Башкарма комитеты 14 эш көне дәвамында гаризаны карый һәм әлеге маршрутны тикшереп чыгуны үткәрү өчен комиссия раслый. Маршрутны тикшереп чыгуны башкаруда киткән чыгымнар, билгеләнгән тәртиптә, Йөртүче тарафыннан түләнә.

Тикшерүне башкару өчен комиссия составына юл, коммуналь һәм карамагында юл, урам, ясалма корылмалар, тимер юл аркылы чыгу урыннары булган башка оешмалар вәкилләре, һәм шулай ук тиешле контроль-күзәтчелек органнары вәкилләре керергә тиеш.

6.4. Комиссия гамәлдәге законнар нигезендә, маршрутны өч көн срок эчендә тикшереп чыга.

6.5. Тикшерү акты, яңа автобус маршруты ачу мәсьәләсе буенча карар кабул итү өчен, районның Башкарма комитетына җибәрелә. Районның Башкарма комитеты 3 эш көне дәвамында яңа маршрут ачу буенча мәсьәләне карый.

6.6. Маршрут гамәлдәге законнарның таләпләренә җавап бирмәгән очракта, район Башкарма комитеты яңа автобус маршруты ачуны кире кагу турында карар кабул ителгәннән соң өч көнлек срокта Йөртүче адресына кире кагу сәбәпләрен дәлилләп белдерү кәгазе җибәрә.

6.7. Маршрут гамәлдәге законнарның таләпләренә җавап биргән очракта, район Башкарма комитеты карар кабул ителгәннән соң өч көнлек срокта Йөртүче адресына яңа коммерцияле автобус маршруты ачуга ризалык турында белдерү кәгазе җибәрә.

6.8. Яңа автобус маршруты ачуга ризалык алган очракта Йөртүче маршрут паспортын һәм схемасын төзергә һәм тиешле дәүләт һәм муниципаль органнарында раслатырга бурычлы. Маршрут паспортына маршрутны характерлаучы мәгълүматлар кертелә: линия корылмалары, туктау пунктлары булуы, алар арасындагы аралар, юлларның торышы һ.б.

Автобус маршрутын тәртипкә китергәндә, пассажир агымы зурлыгына һәм юл шартларына карап, Йөртүче түбәндәгеләрнең булуын күздә тотарга тиеш:

- маршрутның башлангыч һәм соңгы пунктларында транспорт чарасына борылыш һәм туктап тору өчен мәйданчыклар;
- автобус маршрутының туктау пунктларында утырту мәйданчыклары;
- керү өчен махсус мәйданчыклар – “кесәләр”.

Болар булмаган очракта Йөртүче өстәрәк күрсәтелгән мәйданчыкларны булдыру буенча чаралар планын эшләргә, тиешле дәүләт һәм муниципаль органнары белән килештерергә һәм район Башкарма комитетында раслатырга тиеш. Билгеләнгән срокта автобус маршрутын әлеге мәйданчыклар белән тәэмин итәргә.

Файдалануга яңа корылмалар кертелә барган саен Йөртүче маршрут паспортына өстәмәләр кертергә, автобуска кирәк-яраклар алырга (маршрут номеры һәм (яки) исеме, маршрут схемасы, йөрү хакы белән табло), туктау пунктларын җиһазландыруны башкарырга (әлеге маршрут буенча автобуслар хәрәкәте интервалы күрсәткечләрен элү) тиеш.

6.9. Йөртүче билгеләнгән тәртиптә маршрут паспортын, маршрут схемасын, гамәлдәге законнар нигезендә, йөртүчеләрнең хезмәт һәм ял режимнары үтәлешен исәпкә алып, аның аерым участокларында туктау пунктлары арасындагы автобусларның хәрәкәт тизлеге норматив билгеләрен ачыклау нигезендә, хәрәкәт расписаниесен (графигын) эшләргә һәм раслатырга тиеш.

Муниципаль автобус маршрутын кабатлау тыела. Коммерцияле автобус маршруты гамәлдәге муниципаль автобус маршруты белән кисешкән яки өлешчә кабатлаган очракта, Йөртүче әлеге маршрут өлешләрендә хәрәкәт графигын муниципаль автобус маршруты буенча пассажирлар йөртүне Оештыручы белән килештерергә тиеш.

6.10. Йөртүче районның гаммәви мәгълүмат чараларында яңа маршрут ачылуы турында, хәрәкәт юлын, эш режимын күрсәтеп, мәгълүмат бастырып чыгарырга тиеш.

6.11. Коммерцияле автобус маршрутларында пассажир йөртүләрен гамәлгә ашыру өчен йөртүчедә булырга тиеш:

- 8 дән күбрәк кешене йөртү өчен җиһазландырылган автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүгә вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән лицензия;

- гамәлдәге законда билгеләнгән таләпләргә туры килгән персонал (белгечләр, йөртүчеләр, медицина хезмәткәрләре);

- гамәлдәге таләпләргә җавап биргән пассажир автомобиль транспорт чаралары;

- үз милкендәге яки арендаланган производство базасы яки аккредитацияләнгән конкрет транспорт предприятиесендә пассажир автомобиль транспорт чараларын саклау, хезмәт күрсәтү һәм техник хәлен тикшерүне оештыруга килешүләр;

- маршрут схемасы белән маршрут паспорты;

- хәрәкәт расписаниене (графигы);

- башка документлар (пассажирлар йөртү буенча хезмәтнең ярашканлык сертификаты, автомобиль транспортына техник тикшерү үткәрүгә ярашканлык сертификаты, ОСАГО полисы, медицина хезмәткәре сертификаты һ.б.);

Пассажирлар йөртүне башкарган вакытта рөхсәт бирүче һәм башка документлар (лицензия карточкасы, автобуслар хәрәкәтенең расланган һәм килештерелгән расписаниесе (графигы), маршрут схемасы, юл һәм билет-исәпләү кәгазьләре) автотранспорт чарасында булырга тиеш һәм контрольдә тотучы органнар таләбе буенча йөртүче тарафыннан күрсәтелергә тиеш. Өстә күрсәтелгән әлеге рөхсәт бирүче документацияләрне башка йөртүчеләргә тапшыру тыелган.

Алдан килештерелгән һәм расланган автобуслар хәрәкәте маршрутларыннан тайпылу, хәрәкәт расписаниесендә (графигында) каралмаган урыннарда тукталыш ясау, хәрәкәтнең билгеләнгән тизлек режимын арттыру, кирәкле документларсыз йөртүләр гамәлгә ашыру тыела.

Йөртүче пассажирлар йөртүне гамәлдәге законнар, муниципаль хокукый актлар таләпләрен үтәп башкарырга тиеш.

Маршрут паспортын гамәлдән чыгару өчен нигез булып тора:

- маршрутлы пассажирлар йөртү буенча эшчәнлекне регламентлаштырган гамәлдәге законнарның, муниципаль хокукый актларның таләпләрен системалы рәвештә бозу;

- маршрутлы пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы юридик затның ябылуы яки үзгәртеп оештырылуы, банкротлыгы яисә шәхси эшмәкәрнең эшчәнлеге туктатылуы.

- автомобиль транспортында пассажирлар йөртүгә лицензиянең гамәлдә булуын бетерү.

Йөртүче маршрут схемасы белән маршрут паспортын районның Башкарма комитетына илтеп тапшыра.

6.12. Йөртүче коммерцияле автобус маршрутларында пассажирлар йөртүне оештырганда йөртүчеләр составының профессиональ ышанычлылыгын тәэмин итәргә, гамәлдәге законнар, муниципаль хокукый актлар нигезендә, транспорт чарасы техник төзек хәлдә файдаланылуын тәэмин итәгә тиеш.

Туры килгән технологик җиһазлар, приборлар, документацияләр, автомобиль базасы (автостоянка), пассажир транспорт чараларына техник хезмәт күрсәтүче белгечләр булмаса, аларны, килешүләр нигезендә, махсуслаштырылган транспорт предприятиеләрендә урнаштырырга һәм техник хезмәт күрсәтелүен тәэмин итәргә тиеш.

6.13. Йөртүченең бурычлары:

- пассажирлар йөртү өчен Дәүләт юл хәрәкәте куркынычсызлыгы инспекциясе органнарында пассажирлар йөртүче транспорт чарасы буларак теркәлгән, билгеләнгән тәртиптә дәүләт техник тикшерүен үткән һәм билгеләнгән үрнәктә лицензия карточкасы булган хәрәкәттәге составны файдаланырга тиеш;

- көн саен линиягә чыгар алдыннан һәм стоянка урынына кайту белән транспорт чарасының техник торышына контроль оештыру һәм транспорт чарасының техник төзеклеге турында юл кәгазендә тамгалау;

- көн саен транспорт чарасын йөртүчеләргә рейска кадәр һәм рейстан соң медицина каравын башкаруны оештыру, гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртип буенча, аның үткәрелүен юл кәгазендә тамагалау;

- хәрәкәттәге составны махсус бүлеп бирелгән стоянкаларда тоту, хәрәкәттәге составны чыгару һәм кайтаруны билгеләнгән җитәкчелек документлары нигезендә башкару;

- йөртүчеләрне, инструктаж үткәрү юлы белән, маршруттагы хәрәкәт һәм эш шартларында кирәкле оператив мәгълүматлар белән тәэмин итү;

- маршруттагы хәрәкәтнең диспетчер көйләвен гамәлгә ашыру;

- хәрәкәтнең даимилеге, транспорт чарасының техник һәм санитар хәле, пассажирларга хезмәт күрсәтү культурасы һәм Юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәү күрсәткечләре буенча маршрут (линия) контролен башкару;

- автобусларның соңгы пунктлары (туктап тору пунктлары) өчен урыннарны билгеләү;

- пассажирларга билгеләнгән үрнәктәге билет продукциясен сатуны тәэмин итү;

- гамәлдәге законнарның, муниципаль хокукый актларның автомобиль транспортында пассажирлар йөртү өлкәсен регламентлаштыручы таләпләрен үтәү.

6.14. Йөртүченең хокуклары:

- юлларны һәм ясалма корылмаларны төзү һәм төзекләндерүне исәпкә алып, транспортта пассажирлар йөртүне үстерү буенча тәкъдимнәр эшләү;

- яңа маршрутлар ачу буенча тәкъдимнәр формалаштыру;

- йөртүчеләр белән, муниципаль маршрутларда аларның эшен координацияләүне тәэмин итү буенча үзара бәйләнешләрне гамәлгә ашыру;

- пассажирлар йөртүне оештыруны яхшырту буенча тәкъдимнәр кертергә.

## 7. Пассажирлар йөртү артыннан контрольне гамәлгә ашыру

7.1. муниципаль һәм коммерцияле даими автобус маршрутларында пассажирлар йөртүне оештыру һәм гамәлгә ашыру артыннан контрольне башкаручы органнар булып түбәндәгеләр тора:

- үз вәкаләтләре чигендә район Башкарма комитеты;

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Буа районы буенча бүлеге Дәүләт юл хәрәкәте иминлеге инспекциясенең теркәү-имтихан бирү бүлеге;

- үз вәкаләтләре чикләрендә башка органнар.